Хәмидуллина, Р. Өй күрке – мич : [хикәя-дәвамы] / Р. Хәмидуллина // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 12 (20 февраль). – Б. 20.



№ 12 (5248) | Җомга 20 февраль 2026 ел

## ХИКӘЯ

Роза Хәмидуллина

# ӨЙ КҮРКЕ – МИЧ



Дәвамы.
Башы 6 февраль санында

Мәдинә үз чиратында ашарга әзерләү белән мәшгуль булды. Бер үк вакытта мичченең эшенә күз төшереп алырга да өлгерә. Кирпечләр өеменең бер ягтагысы күзгә күренеп кими, ә икенче якта, яңа мич урынындагысы, күзгә күренеп үсә бара иде. ИншәАллаһ, ярыйсы гына була бу, шактый җыйнак, тыйнак моның нигезе, дип, эчтән генә куанып, догаларын укып куярга да онытмый.

Төшке ашны, «әндри әбәтен», кичке ашны да, итне күп салып, тәмле иттереп пешерергә тырышты. Яшел кыяр өлгергән чор, салатын да мулдан әзерләде.

Мичче, өстәлнең байлыгын күреп:

– Бу хәтле ашаткач, эшлисе килмәс бит, әби, бозасың бит син безне, –дип шаяртып та алды.

– Ашаган малда өмет бар, улым, ашагыз барганда, ашар чагыгыз. Менә хәзер эшләп тә, ашап та булмый, без үскән чакта ашарына да юк иде, – дип җавабын да кайтарды.

Мич ярыйсы гына үсеп китте. Мичче әбинең күрсәтмәләрен тайпылмый үти: дүрт таба сыярлык мич эче ясалды, мич калагы урнаштырылды, мич көймәсе куелды...

– Әби, иртәгә дә көн бар, бүгенгә җитәр, – дип, кичке аштан соң, магнитофонын сүндереп, мичче кайтып китте.

Иртәгесе көнне дә егет магнитофон көе астында «биеп кенә» эшләде, аның үз эшенең остасы икәненә шик калмады. Булышчылар да шактый иде. Эш, көлке, мәзәк белән сизелмәде дә.

Мич салынып бетте. Килене бик матурлап мичне агартып та чыкты.

Мәдинәнең куанычы эченә сыймады. Мич чыгаручы егеткә, борынгы һөнәрне улына өйрәтеп калдырган Рухуллага кайта-кайта рәхмәтләрен укыды.

Мичче егет, яңа мичкә кинәттән кызу якмаска, тәмам кибеп беткәч кенә тулы көченә җигәргә кирәклек хакында күрсәтмәләрен биргәч, кайтып китте.

– Кулларыңнан куан, оста! Капкадан чыгып, кулын каш өстенә куеп озатып калган Мәдинәнең мең-мең рәхмәт сүзләрен җилгә каршы элдергән мотоцикл тавышы күмеп китте.

Миччене озатып кергәч, әле яңа гына игътибар итте, оныкларын ашатмаган икән ич әле. Ә алары әбиләрен җитәкләп алдылар да ишегалды читенәрәк кызыл кирпеч ватыкларыннан бизәкләп ясалган «шәһәрчек»ләрен күрсәтергә алып киттеләр. Бәрәкалла, гел чын төсле, «өй»ләренең мич торбалары да чыгып тора, төтеннәре генә күренми. Оныклар әбине ике яклап уратып алдылар һәм:

*Бие, бие, Гайфулла,*
*Биегән кеше бай була,*
*Биегән кеше бай булса да,*
*Кесә төбе сай була.*

– дип, үзе үк өйрәткән көйне такмаклап, тыпырдашып бии башладылар. Мәдинә дә биеде. «Булды, булды, әбиегезне егасыз бит инде», – дип чирәмгә тәгәрәп киткән булды.

Шулчак баскыч башында төпчек малай күренде. Шатлыктан күзләре ялтыраган бәләкәчләр янына килеп:

– Йә, кайсыгыз бригадир, күрсәтегез әле, мин кушканча «төзедегез» микән? – дигән булып «шәһәрчек» янына иелде.

Балалар, берсен-берсе уздырырга тырышып, нидер әйтергә, нидер күрсәтергә ашыктылар, арада берсе аеруча җор сөйли:

– Менә, әти, – ди ул, – менә бу өйдә ясле, менә бу өйдә аш пешерәләр, анда елак сеңлебез тәмле кабартмалар пешерә, эшкә алганыбызны үзенә әйтмәдек әле, бишегендә йокы симертә, – дип, борынын тартып куйды.

Мәдинәнең күзләре чыланды, сөенечтән, әлбәттә.

– Бу ашханәне без «Тәмлетамак» дип атарбыз, – дип, сүзне инде әтиләре дәвам итте, – түрендә һичшиксез әбиегез белән әниегез утырачак. Мичләре дә авыл мичennән ким булмас, кызартып, тәмле итеп пешерә торган булыр... Ә әлегә.., әлегә җитеп торыр, әбиегез ашарга керегез, иртәгә дә көн бар, дип, ничә чыгып чакырды бит инде.

Оныклар йөгерешә-куыша өйгә кереп киттеләр.

Telegramда безнең төркем **shahrichally**

ВКонтактеда безнең төркем **shahrichalli**

Одноклассникида безнең төркем **shrichally. gazetasy**